**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
ЕГОРЬЕВО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ**
422621 Каип авылы,
Үзәк урамы, 50 нчы йорт,
тел: 3-36-19

**ГЛАВА ЕГОРЬЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЛАИШЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422621 с.Каипы,
ул. Центральная, д.50
тел: 3-36-19

**2024 елның 12 августы** **9 номер**

# БОЕРЫК

## Кадастр номерлары 16:24:070802:11419, 16:24:070802:11863, 16:24:070802:13136 булган җир кишәрлекләреннән яисә капиталь төзелеш объектларыннан файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турындагы боерык проекты буенча ачык тыңлаулар билгеләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 39 маддәсе, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Рождествено авыл җирлеге уставы, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Рождествено авыл җирлеге советының 2018 елның 12 декабрендәге 41 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Рождествено авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмә нигезендә, тормыш эшчәнлегенең уңайлы шартларына кеше хокукларын, җир кишәрлекләре һәм капиталь төзелеш объектлары хокук ияләренең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәү максатларында, КАРАР БИРӘМ:

1. Кадастр номерлары 16:24:070802:11419, 16:24:070802:11863, 16:24:070802:13136 булган җир кишәрлекләреннән яисә капиталь төзелеш объектларыннан файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә ТР, Лаеш муниципаль районы, Кызыл Ил авылы адресы буенча урнашкан «Кибетләргә» рөхсәт бирү буенча ачык тыңлаулар билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Егорьево авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләре проектын әзерләү комиссияләре 2024 елның 12 сентябренда 10.00 сәгатьтә Каип авылы, Үзәк урамы 50., башкарма комитеты бинасында ачык тыңлаулар уздырырга.

3. Ачык тыңлауларга чыгарыла торган мәсьәлә буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләрне язма рәвештә түбәндәге адрес буенча җибәрергә: Татарстан

Республикасы Каип авылының Лаеш районы, Үзәк урам, 50. 2024 елның 12 сентябренә кадәр.

4. Әлеге бәяләмәне «Кама ягы» («Камская новь») район газетасында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Егорьево авыл җирлегенең махсус мәгълүмати стендларында урнаштырырга (халыкка җиткерергә).

**Рәислек итүче:**
**Егорьево авыл җирлеге башлыгы**
**вазыйфаларын башкаручы** **И.Б.Зарипов**